ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 22 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 5 өлешендәге 10 пунктында «б» пунктчасында» сүзләрен «а» һәм (яисә) «б» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «в» пунктчасындагы дүртенче абзацында каралган нигезләмә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында 2021 елның 1 апреленә кадәр төзелгән килешүләр

нигезендә проектларны гамәлгә ашыра торган һәм Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә чыгымнарны каплый торган оешмаларга карата кулланылмый.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 09 март
№ 11-ТРЗ